**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

22.11.2017 ел Яр Чаллы № 5186

Тукай муниципаль районы гомуми белем
бирү оешмаларын норматив финанслау турында

«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 08 августындагы 566 номерлы карары нигезендә һәм гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, төп гомуми белем бирү муниципаль белем бирү хезмәтенең сыйфатын арттыру максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кушымта нигезендә расларга.
2. Башкарма комитет җитәкчесенең «Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 12 декабрендәге 280 номерлы карары үз көчен югалткан танырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.Р. Исаевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Т. Гыйзатуллина